**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 18 октябрь № 754

г. Казань

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын «Иннополис шәһәре» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең «Иннополис шәһәре» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына Татарстан Республикасын кертү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы исеменнән «Иннополис шәһәре» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы башкара дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

«Иннополис шәһәре» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына керергә;

«Иннополис шәһәре» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составына керү белән бәйле чаралар үткәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков